**ГЛАВА АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 22 нче йорт
Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 7 октябре №1

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. М.Җәлил урамы буенча 12 нчы йорт янында 2022 елның 20 октябрендә 8.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Нариман урамы буенча 10 нчы йорт янында 2022 елның 20 октябрендә 9.30 сәгатькә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Акъяр Мәдәният йортында (Совет урамы, 20 нче йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2022 елның 20 октябрендә 11.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Акъяр авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
5. Гражданнар Җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2023 нче елга, 600 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаиләләре азат ителә. Үзара салым түләүдән җыелган акчаларны түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (юлларны ташландыру, сатып алу, китерү, таш түшәү, килешү буенча эшләр өчен түләү) Яшьләр урамы, Ленин урамы буенча;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары,автомашинага тагылма арба , запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
-- объектларга һәм су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт (материал сатып алу, агымдагы ремонт, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш өчен түләү, шул исәптән суктыру операторына да);
-- юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча түләү;
- зиратны төзекләндерү (территорияләрне чабу, материал сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү);
- чокыр, күпер буенда киртәләрне сатып алу һәм монтажлау (материал алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) Нариманов урамы, Тукай урамы буенча.

“ӘЙЕ” “ЮК”.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуцион челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ ,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авылы, Советская ур., 22 мәгълүмат стендында гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча.

8. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы: Д. С. Гайнуллин